**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Иске Барыш авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**2019 елның 16 апреле** **№ 107**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советының 2017 елның 9 октябрендәге “Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында”гы Нигезләмә хакында” 49нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү сәбәпле, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Советы гамәлдәге законнарга туры китерү максатында КАРАР чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советының 2017 елның 9 октябрендәге 49 номерлы карары белән расланган Иске Барыш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Иске Барыш авылы, Үзәк ур., 15 нче йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Кыртапа авылы, Мәктәп ур., 10 нчы йорт,
шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Иске Барыш авыл җирлеге Башлыгы,**
**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Иске Барыш авыл җирлеге Советы рәисе** **И.Р.Җиһаншин**